СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.02.2019 ел Баулы шәһәре № 196

Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 3 июлендә кабул ителгән 159 номерлы «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Баулы шәһәр прокурорының 2019 елның 29 гыйнварындагы 02-08-02 номерлы протестын карап һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 июлендәге 192-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турында закончалыгының үтәлешен контрольдә тотуны камилләштерү максатында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 3 августындагы 307-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 октябрендәге 382-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законның 7 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 559-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Баулы муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 3 июлендә кабул ителгән 159нчы номерлы «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль

районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

15нче статьяга түбәндәге эчтәлекле 1.2 пункт өстәргә:

«1.2. Гражданин, муниципаль хезмәткәр, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән туган булса (ата-анасы, ире яки хатныны, балалары, абыйлары, сеңелләре, апалары, ире яки хатынының ата-аналары, балалары һәм балаларының ире яки хатыны) «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең тикшерү-хисап органы рәисе, рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфасына билгеләнә алмый. »;

15 статьяның 1 өлешендәге 10 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«10) хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе бәяләмәсе нигезендә, законлы нигезләр булмый торып, чакырылыш буенча хәрби хезмәтне үтмәгән дип танылу (контракт буенча хәрби хезмәт үткән гражданнардан тыш) – күрсәтелгән бәяләмәгә карата Россия Федерациясенең тиешле субъекты хәрби комиссиясенә шикаять бирү срогы чыкканнан соң 10 ел эчендә, әгәр күрсәтелгән бәяләмә һәм (яисә) Россия Федерациясенең тиешле субъекты хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе карары буенча судка шикаять бирелгән булса, - күрсәтелгән бәяләмәне һәм (яисә) Россия Федерациясенең тиешле субъекты хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе карарын чыгарганда граждан хокуклары бозылмаган дип тану турында суд карары законлы көченә кергән көннән 10 ел эчендә.»

16нчы статьяга түбәндәге эчтәлекле 4нче өлеш өстәргә:

«4. Җитәкче булган муниципаль хезмәткәр, әлеге вазыйфаны биләгән чорда, җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты профсоюз органына керә алмый.»;

16 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Шәхсән яки ышанычлы затлар аркылы эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашудан тыш; съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милекчеләр иптәшлеге гомуми җыелышында катнашудан тыш; муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә алынган эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән, бердәнбер башкарма орган яки коллегиаль идарә итү органнары составына керү сыйфатында әлеге коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашудан тыш (сәяси партиядән һәм һөнәри Союз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан тыш),

муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы яки муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә муниципаль берәмлек гамәлгә куйган (акционеры, катнашучысы булган) идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен тәкъдим итүдән тыш; федераль законнарда каралган башка очракларда».,

33 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:

«2.1) Баулы муниципаль районы Советы Аппаратының кадрлар белән тәэмин итү бүлегенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча коррупцион хокук бозу турында доклады (аны башкаруның факттагы шартлары бәян итеп) һәм муниципаль хезмәткәрнең (бары тик аның ризалыгы һәм коррупцион хокук бозу фактын тану шарты

белән генә) язмача аңлатмасы (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендә җәза бирелмәгән булса);»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Баулы муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин